| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Старомензелябашского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.03.2026 № 25

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советының «Физик затлар
мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел,
№ 15 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел, № 15 карарына (29.05.2015 ел, № 11 , 20.10.2015 ел № 7, 22.06.2018 ел, № 8, 21.11.2018 ел, № 24, 21.03.2020 ел, № 5, 07.11.2024 ел № 14, 23.11.2024 ел № 22а, 16.12.2025ел № 12 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәреш кертергә:
   «2 пунктның 2.4.3 пунктчасында «, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш»сүзләрен өстәргә;».
2. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел, № 15 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 20.02.2026 ел, № 23 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Н.Габдрахманов